# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елда Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Мәсгүт авыл җирлегендә,
Мәсгүт торак пунктында
үзара салым кертү турында

**25 октябрь 2024 ел.** **№ 4**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авыл җирлеге Мәсгүт торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгүт авыл җирлеге Мәсгүт торак пунктында 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән карата 500 сум күләмендә, гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән, хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаиләләр, 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә билгеләргә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алыштыру, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут торак пунктында урамнарны яктыртуны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү хезмәтләре күрсәтү);
- Торак пункт территориясен төзекләндерү (Дуслык урамындагы урнашкан чишмәне төзекләндерү һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут торак пункты территориясен яшелләндерү );
- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татарстан Республикасы Азнакай МР Мәсгут торак пунктындагы юлларны профильләштерү һәм вак таш түшәү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында, Мәсгүт авыл җирлегенең Мәсгүт торак пунктында мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Мәсгүт авыл җирлеге
башлыгы: И.А.Вильданов